ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12 сентября 2024г. № 5920

Башкарма комитетның «Биналарның фасадларына өстәмә җиһаз урнаштыру буенча архитектура йөкләмәсе әзерләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 7 маендагы 3183 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең 126.2 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Биналарның фасадларына өстәмә җиһаз урнаштыру буенча архитектура йөкләмәсе әзерләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 7 маендагы 3183 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «, Башкарма комитетның «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2021 елның 3 мартындагы 1441 номерлы карары» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) биналарның фасадларына өстәмә җиһаз урнаштыру буенча архитектура йөкләмәсе әзерләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

- 5.1 пунктның 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1. статьясында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны теркәү срогын бозу;»;

- 5.3 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга, муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югары органга (ул булганда) килгән шикаять, аны теркәгән көннән

башлап унбиш эш көне эчендә, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять бирелгән очракта яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга шикаять бирелгән очракта – аны теркәгән көннән башлап биш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш.»;

- 5.5 пунктның 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;»;

- 5.8 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11.2 статьясының 1 өлеше нигезендә шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары М.Ә. Фәттаховка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов